| ГЛАВА САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 8 03.11.2025

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Өчиле Саклау авылында 2026 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 22 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Уставы: нигезендә карар бирәм:

1. Өчөйле Саклау авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 14 нче ноябрь 2025 нчы ел 13:00 сәгатькә билгеләргә.. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2026 елда үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Өчиле Саклау торак пункты чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү гидранты кую)

2) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, вак таш җәю, юлларны кардан чистарту, үлән чабу);

3) Өчиле Саклау торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау (лампалар сатып алу һәм алыштыру)

4) Өчиле Саклау торак пункт территориясен төзекләндерү (территорядәге үләннәрне чабу, килешү буенча эш һәм күрсәтелгән хезмәтләрне түләү)

5) Халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләү (төзелеш материаллары сатып алу һәм ял паркы ясау)

ДА НЕТ?».

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Саклаубаш, Өчөйле Саклау, Алга, Яңа Саклау авылларында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.
4. Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының «Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле Саклау торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында " 2025 елның 31 октябрендәге 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саклаубаш авыл
җирлеге башлыгы Л.М.Габидуллина